КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 6 декабрь г.Казань № 940

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 ел, 3 март, 130 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2015 ел, 3 март, 130 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә «һәм аларны савыктыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

преамбулада «һәм аларны савыктыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «һәм аларны савыктыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республика муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына муниципаль учреждениеләр күрсәтә торган тиешле муниципаль хезмәтләр сыйфатын бәяләү өчен бу карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын файдалануны тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

исемендә «һәм аларны савыктыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

I бүлекнең 1 пунктында «һәм аларны савыктыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

II бүлектә:

бишенче абзацта «гыйнвар» сүзен «декабрь» сүзенә алмаштырырга;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 2016 ел, 31 март, 191 нче карары;

II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтә торган медицина оешмаларында файдаланыла торган медицина документларының унификацияләнгән формаларын раслау турында» 2014 ел, 15 декабрь, 834н боерыгы.»;

III бүлектә таблицада:

2 пунктның 3 графасында «Федераль миграция хезмәтенең территориаль органнары һәм аларның структур бүлекчәләре» сүзләрен «Россия Федерациясенең Эчке эшләр министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның 2 графасында «СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының «Сәламәтлек саклау учреждениеләренең беренчел медицина документлары формаларын раслау турында» 1980 ел, 04 октябрь, 1030 нчы боерыгы белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының « Амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтә торган медицина оешмаларында файдаланыла торган медицина документларының унификацияләнгән формаларын һәм аларны тутыру тәртипләрен раслау турында» 2014 ел, 15 декабрь, 834н боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның 2 графасында «Балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләрдә һәм бүлекчәләрдә исәптә торучы балалар исемлекләре» сүзләрен «Балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләрдә һәм бүлекчәләрдә балалар исәбен алып баруны раслый торган документлар» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта:

2 графада «Россия Федерациясе субъектларыннан һәм якын һәм ерак чит илләрдән җибәрелгән балалар һәм яшьләр өчен сменалар оештырганда төзелгән халыкара һәм төбәкара килешүләр нигезендә гаризалар һәм исемлекләр» сүзләрен «Дәүләт һәм ведомство бүләкләре, дәүләт премияләре һәм мактау билгеләре турында документлар» сүзләренә алмаштырырга;

3 графада «башкарма хакимият дәүләт органнары» сүзләрен «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлектә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Шәхеснең белем алу һәм иҗади потенциалын үстерүне тәэмин итү, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту, авыруларны профилактикалау, организмны чыныктыру, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыру, балигъ булмаганнарның күзәтүсезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау, иҗтимагый файдалы һәм җитештерүчән хезмәт, физик культура, спорт, туристлык белән шөгыльләнү дәүләт хезмәте күрсәтүнең төп максаты булып тора.»;

3 пунктта «, аларны савыктыруны, эш белән тәэмин итүне» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктның икенче абзацында «һәм савыктыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Дәүләт хезмәте күрсәтү формалары.

Шәһәр читендәге ял лагерында смена – бу каникул чорында стационар базада укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек әйләнәсе торып үткәрелә торган балалар белән ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Җәйге ялларда смена озынлыгы кимендә 21 көн, көзге, кышкы һәм язгы каникулларда кимендә җиде көн була.

Шәһәр читендәге ял лагерында профильле смена – бу ел дәвамында стационар базада укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек әйләнәсе торып үткәрелә торган иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары активы, республика, бөтенроссия, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләре һәм призерлары белән ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Җәйге чорда смена озынлыгы кимендә 18 көн, көзге, кышкы һәм язгы чорда кимендә җиде көн була.

Палатка тибындагы лагерьда профильле смена – бу каникул чорында кыр шартларында укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек әйләнәсе торып үткәрелә торган иҗади сәләтле балалар белән (яшь техниклар, туган якны өйрәнүче туристлар, экологлар, спортчылар, математиклар, филологлар, журналистлар, коткаручылар, диңгезчеләр, автомобильчеләр, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары активы) ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Сменаның тәкъдим ителә торган озынлыгы – палатка тибындагы лагерьда 5 – 21 көн. Күчмә лагерьда смена озынлыгы әзерлексез, беренче тапкыр катнашучы балалар өчен – ике-өч көннән артык түгел, әзерләнгән, туристлык берләшмәләрендә шөгыльләнүче балалар өчен – җиде көннән артык түгел. Палаткалы лагерьда җиде көннән артык озынлыкта смена оештырылганда балаларны юындыру оештырылырга тиеш.

Кара диңгез ярында профильле смена – бу Кара диңгез ярында стационар базада укучылар тәүлек әйләнәсе торып үткәрелә торган иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары активы, республика, бөтенроссия, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләре һәм призерлары белән ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Җәйге чорда смена озынлыгы кимендә 14 көн, көзге, кышкы һәм язгы чорда кимендә җиде көн була.

Мәгариф оешмасы оештырган көндез булу лагерында смена – бу каникул чорында мәгариф оешмасы укучылары белән нигездә мәгариф оешмасы базасында үткәрелә торган укучылар көндезге вакытта була торган һәм мәҗбүри рәвештә аларның туклану оештырылган ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Смена озынлыгы каникуллар дәвамлыгы белән билгеләнә һәм җәйге каникул чорында 21 календарь көне, көзге, кышкы һәм язгы каникулларда кимендә җиде көн була.

Хезмәт һәм ял лагерында смена – бу каникул чорында җәмгыятькә файдалы хезмәт оешмасы белән нигездә мәгариф оешмасы базасында үткәрелә торган укучылар көндезге вакытта була торган һәм аларның туклану оештырылган ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Сменанвың озынлыгы – 24 календарь көненнән артык түгел.

Санаторния-курорт ял оешмаларында смена – бу укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек әйләнәсе санаторния-курорт учреждениесендә торып һәм тернәкләндерү һәм (яки) торгызу дәвалауы чараларын мәҗбүри оештыру үткәрелә торган балалар һәм яшьләр белән ял итү формасы. Смена озынлыгы – кимендә 24 календарь көне.

Югары белемнең белем бирү студентлары өчен физкультура-сәламәтләндерү чаралары – бу укучылар белән тәүлек әйләнәсе яки көндезге вакытта була торган һәм мәҗбүри рәвештә аларның туклану оештырылган югары белемнең белем бирү оешмаларында укучылар белән белем бирү эшчәнлеге формасы.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Дәүләт хезмәтен алуның календарь чоры:

| Т/с | Лагерьлар формалары күзлегенншән дәүләт хезмәте күрсәтү | Алу чоры |
|---|---|---|
| 1. | Шәһәр читендәге ял лагерында смена, шәһәр читендәге ял лагерында профильле смена, мәгариф оешмасы оештырган көндез булу лагерында смена, хезмәт һәм ял лагерында смена | ел дәвамында каникуллар чорлары |
| 2. | Палатка тибындагы лагерьда профильле смена | җәйге каникул чоры |
| 3. | Кара диңгез ярында профильле смена | сезонга бәйле каникуллар чорлары |
| 4. | Санаторния-курорт ял оешмаларында смена | ел дәвамында |
| 5. | Физкультура-сәламәтләндерү чаралары | ел дәвамында»; |

VI бүлекнең 3 пунктында «һәм савыктыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

VII бүлекнең 6 пунктының икенче абзацында «һәм савыктыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

VIII бүлектә:

2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шәхес гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм дәрәҗәсенә (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз госпитализацияләнүдән һәм яладан тыш), шәхеснең җенесе иминлегенә һәм җенесе ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халык сәламәтлегенә һәм җәмәгать әхлагына, дәүләтнең конституцион төзелешенә һәм иминлегенә, тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә каршы, шулай ук иҗтимагый куркынычсызлыкка каршы җинаять кылган өчен суд хөкеме булган, җинаять эзәрлекләүенә дучар ителгән (аклаучы нигезләр буенча аларга карата җинаять эзәрлекләүе туктатылган затлардан тыш);»;

түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

«2.1. Әлеге бүлекнең 2 пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән шәхес гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм дәрәҗәсенә (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз госпитализацияләнүдән һәм яладан тыш), шәхеснең җенесе иминлегенә һәм җенесе

ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халык сәламәтлегенә һәм җәмәгать әхлагына, дәүләтнең конституцион төзелешенә һәм иминлегенә, тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә каршы, шулай ук иҗтимагый куркынычсызлыкка каршы җинаять кылган өчен суд хөкеме булган, җинаять эзәрлекләүенә дучар ителгәннәр арасыннан затларга һәм бу җинаятьләрне кылуда гаепләү буенча җинаять эзәрлекләүе акламаучы нигезләр буенча туктатылган затларга Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы төзегән балигъ булмаганнар һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия карары булганда педагогика эшчәнлеге рөхсәт ителә.»;

IX бүлекнең 4 пунктында «һәм савыктыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

X бүлектә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Алучы дәүләт хезмәтен бирүдә түбәндәге нигезләр буенча баш тартылырга мөмкин:»;

өченче абзацта «һәм савыктыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

XI бүлектәге таблицаның 3 пунктындагы 2 графада «Дәүләт хезмәтен алучылар алган сизелерлек нәтиҗәле сәламәтләндерү» сүзләрен «Дәүләт хезмәтен алу нәтиҗәләре буенча сәламәтлек торышының төп күрсәткечләрен үзгәртү» сүзләренә алмаштырырга;

XII бүлекнең 12.5 пунктында «эшче» сүзен төшереп калдырырга;

XIV бүлектә:

1 пунктта «һәм савыктыруны» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта «балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыруга» сүзләрен «Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүгә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин